# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм "Алабуга муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 22 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

Покровский авылында яшәүче халыкның тавыш бирү юлы белән белдерелгән ризалыгы нигезендә, "Костенеево авыл җирлеге", "Мурзиха авыл җирлеге" һәм "Алабуга шәһәре" муниципаль берәмлекләренең вәкиллекле органнары фикерен исәпкә алып, әлеге Закон нигезендә Алабуга муниципаль районы составына керүче түбәндәге муниципаль берәмлекләрнең чикләрен үзгәртергә:

1) "Костенеево авыл җирлеген" аның составына янәшәсендәге Мурзиха авыл җирлеге территориясе белән Покровский авылын һәм "Алабуга шәһәре" муниципаль берәмлегенең Түбән Кама муниципаль районы һәм Алабуга муниципаль районы белән чиктәш җирдә урнашкан басу аша кишәрлеген кертү юлы белән;

2) "Мурзиха авыл җирлеген" аның составындагы Покровский авылын янәшәсендәге территориясе белән Костенеево авыл җирлеге составына кертү юлы белән;

3) "Алабуга шәһәрен" "Алабуга шәһәре" муниципаль берәмлегенең Түбән Кама муниципаль районы һәм Алабуга муниципаль районы белән чиктәш җирдә урнашкан басу аша кишәрлеген Костенеево авыл җирлеге составына кертү юлы белән.


**2 статья**

"Алабуга муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" 2005 елның 31 гыйнварындагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (II өлеш); 2008, № 12 (VIII өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Алабуга муниципаль районы"
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү һәм
аларның статусы турында" Татарстан
Республикасы Законына
1 нче кушымта

# "Алабуга муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре
# **карта-схемасы**




Шартлы билгеләр

- республика чиге
- муниципаль район чиге
- 10 - тоташу ноктасының тәртип саны
- 10 - җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлек үзәге

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| 4(16)-3(17) | - Удмурт Республикасы |
| 3(17)-6(215) | - Менделеевск муниципаль районы |
| 6(215)-8(216) | - Удмурт Республикасы |
| 8(216)-23(64) | - Менделеевск муниципаль районы |
| 23(64)-42 | - Тукай муниципаль районы |
| 42-35(63) | - "Чаллы шәһәре" муниципаль берәмлеге |
| 35(63)-31(62) | - Тукай муниципаль районы |
| 31(62)-38(61) | - Түбән Кама муниципаль районы |
| 38(61)-4(16) | - Мамадыш муниципаль районы |

"Алабуга муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Алабуга шәһәре |
| 2 | Илмәт авыл җирлеге |
| 3 | Бехтерев авыл җирлеге |
| 4 | Олы Елово авыл җирлеге |
| 5 | Олы Качык авыл җирлеге |
| 6 | Олы Шүрнәк авыл җирлеге |
| 7 | Костенеево авыл җирлеге |
| 8 | Лекарево авыл җирлеге |
| 9 | Морт авыл җирлеге |
| 10 | Мурзиха авыл җирлеге |
| 11 | Поспелово авыл җирлеге |
| 12 | Иске Күклек авыл җирлеге |
| 13 | Иске Юраш авыл җирлеге |
| 14 | Танай авыл җирлеге |
| 15 | Татар Дөм-Дөме авыл җирлеге |
| 16 | Яковлево авыл җирлеге"; |

2) 3 нче кушымтада:

а) икенче абзацта "Мурзиха," сүзен төшереп калдырырга;

б) уникенче – ундүртенче абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

3) 9 нчы кушымтада:

а) икенче абзацта "Мурзиха," сүзеннән соң "Танай," сүзен өстәргә;

б) бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Костенеево авыл җирлеге чиге Мурзиха авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 32 нче тоташу ноктасыннан алып 5,3 км төньяк-көнчыгышка таба Анзирка елгасы агымы буенча өскә таба аңа инеш койган урынга кадәр уза, Казан – Уфа автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 2,8 км көньяк-көнчыгышка таба шушы инеш буенча уза, аннары 6,5 км төньяк-көнчыгышка таба әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге буйлап Костенеево, Лекарево, Мурзиха һәм Танай авыл җирлекләре чикләре тоташкан

урында Олы Армалы авылыннан 2,8 км көньяк-көнбатышта урнашкан 30 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.";

в) алтынчы абзацта "36 нчы тоташу ноктасыннан" сүзләрен "Костенеево, Танай авыл җирлекләре һәм Түбән Кама муниципаль районы чикләре тоташкан урында Кама елгасы акваториясендә урнашкан X=465770,63, Y=2285497,92 координаталы 34 нче тоташу ноктасыннан" сүзләренә алмаштырырга;

г) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Костенеево авыл җирлеге чиге Танай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 30 нчы тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 1,9 км көньяк-көнчыгышка таба урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 650 м "Алабуга урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Морт участок урманчылыгындагы 71 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң бу урман кварталы буйлап 120 м көнчыгышка таба һәм 310 м көньяк-көнчыгышка таба уза, аннары шул ук юнәлештә 1,3 км инеш буйлап Криуша елгасына кадәр бара, 800 м көньяк-көнбатышка таба шушы елга буенча Кама елгасына кадәр уза, алга таба шушы елга акваториясе буенча 600 м көньякка таба һәм 2,8 км көньяк-көнчыгышка таба 34 нче тоташу ноктасына кадәр бара.";

4) 10 нчы кушымтаның алтынчы абзацында "Лекарево, Мурзиха һәм Танай авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында" сүзләрен "Костенеево, Лекарево, Мурзиха һәм Танай авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында" сүзләренә алмаштырырга;

5) 12 нче кушымтада:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Мурзиха авыл җирлеге Олы Елово, Костенеево, Лекарево, Морт һәм Яковлево авыл җирлекләре белән чиктәш.";

б) дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Мурзиха авыл җирлеге чиге Костенеево авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Костенеево, Мурзиха һәм Яковлево авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Костенеево авылыннан 1,6 км төньяк-көнбатышта урнашкан 32 нче тоташу ноктасыннан алып 5,3 км төньяк-көнчыгышка таба Анзирка елгасы агымы буенча өскә таба аңа инеш койган урынга кадәр уза, Казан – Уфа автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 2,8 км көньяк-көнчыгышка таба шушы инеш буенча уза, аннары 6,5 км төньяк-көнчыгышка таба әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге буйлап Костенеево, Лекарево, Мурзиха һәм Танай авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Олы Армалы

авылыннан 2,8 км көньяк-көнбатышта урнашкан 30 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.";

в) сигезенче абзацта "Лекарево, Мурзиха һәм Танай авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Олы Армалы авылыннан 2,8 км көньяк-көнбатышта урнашкан" сүзләрен төшереп калдырырга;

г) тугызынчы – унберенче абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

б) 16 нчы кушымтада:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Танай авыл җирлеге "Алабуга шәһәре" муниципаль берәмлеге, Олы Качык, Костенеево, Лекарево авыл җирлекләре һәм Түбән Кама муниципаль районы белән чиктәш.";

б) дүртенче абзацта "Мурзиха авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Лекарево, Мурзиха һәм Танай авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Олы Армалы авылыннан 2,8 км көньяк-көнбатышта урнашкан 30 нчы тоташу ноктасыннан алып" сүзләрен "Костенеево авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Костенеево, Лекарево, Мурзиха һәм Танай авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Олы Армалы авылыннан 2,8 км көньяк-көнбатышта урнашкан 30 нчы тоташу ноктасыннан алып" сүзләренә алмаштырырга, "Мурзиха, Танай авыл җирлекләре һәм Түбән Кама муниципаль районы чикләре тоташкан урында Кама елгасы акваториясендә урнашкан X=465770,63, Y=2285497,92 координаталы 34 нче тоташу ноктасына" сүзләрен "Костенеево, Танай авыл җирлекләре һәм Түбән Кама муниципаль районы чикләре тоташкан урында Кама елгасы акваториясендә урнашкан X=465770,63, Y=2285497,92 координаталы 34 нче тоташу ноктасына" сүзләренә алмаштырырга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2010 елның 22 мае
№ 23-ТРЗ